Республика Татарстан

СОВЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 57, д.Шарлиарема
423378
Телефон: 4-57-55

Татарстан Республикасы

САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, йорт 57, Шәрләрәмә авылы 423378
Телефон: 4-57-55

ОГРН 1121651003671 ИНН/КПП 1636007010/163601001 ОКТМО 92653482

# КАРАР

№ 73
2018 елның 17 сентябре

**Шәрләрәмә авылы**

## Референдум уздыруны инициацияләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"2019 елда үзара салым кертүгә Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

1. Ял вакытын оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру.

2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.

3. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

4. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту.

5. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.

6. Җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру.

ӘЙЕ ЮК».

Әлеге карар мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Хуҗина